ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.10.2025 ел Баулы шәһәре № 134

2026 елда Баулы муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклану белән тәэмин итү турында

Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тулы кыйммәтле туклану белән тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны оештыруга һәм түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына булган белем бирү программалары буенча бер укучыга кайнар туклануның уртача бәясен раслау турында» 2026 елның 22 сентябрендәге 726 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны тукландыруны тәэмин итү бәясенең нормативларын раслау турында» 2025 елның 3 октябрендәге 787 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Районның һәм шәһәрнең гомуми белем бирү оешмаларында кайнар туклануны ташламалы шартларда оештыручы предприятиеләргә Баулы муниципаль районы бюджетыннан субвенцияләр бирү буенча Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтле органы итеп «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ билгеләргә.

2. 2026 елның 1 гыйнварыннан Баулы муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмасында уку чорында бер укучыга көнгә кайнар туклану хакы күләмен билгеләргә:

бюджет исәбеннән:

- шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү оешмаларының 1-4 сыйныф укучылары өчен-77 сум 76 тиен;

- 5-11 сыйныф укучылары өчен - 10 сум 70 тиен;

ата-ана кертемнәре исәбеннән:

- 5-11 сыйныф укучылары өчен:

шәһәрдә: иртәнге аш - 18 сум 35 тиен, төшке аш – 59 сум 43 тиен, озайтылган көн төркеме - 24 сум 46 тиен;

авылда: иртәнге аш - 18 сум 35 тиен, төшке аш – 46 сум 23 тиен.

3. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ начальнигы Д.З. Ганиевага «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» (алга таба - БҮЦП) дәүләт мәгълүмат системасын куллану юлы белән муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклану белән тәэмин итү турында мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм БҮЦП операторы билгеләгән форматлар нигезендә җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров